Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Светлоозерского
сельского поселения Заинского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл
җирлегенең
башкарма комитеты

ул. Фардеева, д.15, с. Светлое Озеро,
Заинский район, 423538

Фардеев урамы, 15нче йорт, Якты Күл
авылы, Зәй районы, 423538

Телефон, факс 68-2-88. Электронный адрес: Svoz.Zai@tatar.ru, сайт:
http://zainsk.tatarstan.ru/rus/svetloozerskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**06.02.2023 ел.**

**КАРАР**
**№ 3**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2023 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте 2023 елның 30 январендагы 119 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Уставына таянып

**карар бирәм:**

1. 2023 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 7793,48 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында” 2022 елның 02 февралендәге 3 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **З. З. Мөхтәров**

Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл җирлеге
башкарма комитетының
06.02.2023 ел. 3 номерлы
карарына 1 нче кушымта

2023 елның 01 февраленнән
Якты Күл авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 964,25 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1266,98 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3652,25 |
| Барысы | 7793,48 |

Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл җирлеге
башкарма комитетының
06.02.2023 ел. 3 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Якты Күл авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 812,8 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2212,17 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1236,69 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3531,82 |
| Барысы | 7793,48 |